**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 июль 462

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь,1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә эшчәнлекләрен тормышка ашыра торган идарәче оешмалар, торак милекчеләре иптәшлекләре, торак кооперативлары, бүтән махсуслашкан кулланучылар кооперативлары (алга таба ИК);»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хосусый торак фондында яки күпфатирлы торак фондында яшәүче гражданнар белән турыдан-туры төзелгән шартнамәләр буенча халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмалар (алга таба – ТКХК);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«идарәче яки ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килешүләр буенча торак-коммуналь хезмәтләр өчен акча исәпләүне гамәлгә ашыручы оешмалар (алга таба – ХҮ).»;

6 пунктның таблицасында:

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | ИК, ТКХК, ХҮ | Гамәлдә күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр, антенна хезмәтләре өчен түләүләр турында мәгълүматларны исәпләү һәм тапшыру, персональ-ләштерелгән социаль счетлар күзлегеннән караганда коммуналь хезмәтләр куллану нормативлары, гражданнар тарафыннан 2 айга, шулай ук тоташтан 3 ай һәм артыграк чорда торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен агымдагы түләүләрне түләмәү факты турында, җыелган бурычларын түли башлау факты хакында яки аны түләү буенча килешү төзү һәм (яки) аны үти башлау хакында, коммуналь хезмәтләрне өзү факты, коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты турында мәгълү-матларны исәпләү һәм тапшыру | электрон | хисап аеннан соң килүче айның 3сенә кадәр | МПРҮ бүлекләре»; |

21 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «21. | МПРҮ бүлекләре | Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә натураль рәвештә ташламалар ала торган гражданнар турында мәгълүмат (социаль нормативлар, ташламалар катего-рияләре, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү вакыты һ.б.). Хосусыйлаштырылган социаль счетлар бирелеп һәм бирелмичә ИК, ТКХК, ХҮ шәхси счетлары реестрын тапшыру | электрон | түләү аеның 25енә кадәр | ИК, ТКХК, ХҮ |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков